**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 10 июнь № 391

г. Казань

Дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә өстәмә ярдәм күрсәтү турында

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы карамагындагы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә өстәмә ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Хезмәт шартларын махсус бәяләү нәтиҗәләре белән расланган зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә әлеге карарга кушымтадагы исемлек нигезендә еллык өстәмә түләүле ял билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән максатларга чыгымнар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча 1002 нче «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү» бүлекчәсендә каралган акча кысаларында гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 10 июнь, 391 нче
карарына кушымта

Хезмәткәрләренә еллык өстәмә түләүле ял билгеләнә торган Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмалары
ИСЕМЛЕГЕ

| Т/с | Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмасы төре | Профессияләр исеме <*> | Өстәмә ял озынлыгы, календарь көннәре |
|---|---|---|---|
| 1. | Психоневрология интернаты | бала караучы | 35 |
| | | хуҗалык туташы | 14 |
| 2. | Картлар һәм инвалидлар өчен интернат йорт, картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат йорт | бала караучы, хуҗалык туташы | 14 |
| 3. | Инвалидларны тернәкләндерү үзәге | бала караучы, хуҗалык туташы | 14 |
| 4. | Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәге | бала караучы, хуҗалык туташы | 14 |

<*> Эшчеләр һөнәрләре исемнәре Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль яклау министрлыгының «Эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәрен раслау турында» 2008 ел, 29 май, 248н номерлы боерыгы белән расланган Эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре нигезендә күрсәтелә.

_______________________________